КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 228

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 декабрь, 1305 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «субъектларның башкарма хакимияте органнарына» сүзләрен «субъектларның башкарма органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган

гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенең 7 пунктында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин